**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 июнь № 446

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртипләрен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртипләрен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 июль, 477 нче; 2014 ел, 26 апрель, 270 нче; 2015 ел, 30 апрель, 301 нче; 2016 ел, 25 февраль, 115 нче; 2016 ел, 26 май, 358 нче; 2017 ел, 28 февраль, 119 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 13 нче пункт өстәргә:

«13. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 ел, 29 ноябрь, ФЗ-326 нчы Федераль законның 51 статьясында билгеләнгән медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен шартларның үтәлешен тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\446.doc